ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.12.2020 ел Баулы шәһәре №241

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 28 декабрендәге
485 номерлы «2019-2021 елларга
Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының шәхси
ярдәмче хуҗалыкларын тотрыклы
үстерү» муниципаль программасын
раслау турында» карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү һәм Баулы муниципаль районы территориясендә сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү исәбенә терлекчелек продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыру максатларында «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (елның 27 июнендәге редакциядә) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 декабрендәге 485 номерлы «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын тотрыклы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» (карар, Программа) карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

Программада (карарга 1нче кушымта):

- «Программа паспорты» I бүлегендә «Программаны финанслау чыганаклары» юлындагы 2нче баганаың эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны гамәлгә ашыруга финанс чараларының гомуми ихтыяҗы - 828 600,00 сум, шулардан 2019

елда - 461 100,00 сум, 2020 елда 367 500 сум (җирле бюджет акчасы).

Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм аңа ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

1нче «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү буенча төп күрсәткечләр» кушымтасын өстәргә;

- 2нче «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тотрыклы үстерү» муниципаль программасының төп чаралары исемлеге” кушымтасын өстәргә;

карарга 4нче «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү турында килешү» кушымтасын гамәлдән чыккан дип санарга;

5нче, 6нчы, 7нче, 8нче, 9нчы кушымталарны 4нче, 5нче, 6нчы, 7нче, 8нче кушымталар дип санарга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларны тотрыклы үстерү»
муниципаль программасына
1нче кушымта

2019-2021 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү буенча төп күрсәткечләр

| № п/п | Наименование показателя | Үлчәү бер. | 2018 (факт) | 2019 (факт) | 2020 бәя | 2021 бәя |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны | бер. | 6110 | 6110 | 6110 | 6110 |
| 2. | Крестьян-фермерлык хуҗалыклары саны | бер. | 43 | 46 | 49 | 53 |
| 3. | Мөгезле эре терлек саны, шул исәптән, шул исәптән барлыгы:<br>Шул исәптән: | бер. | 4540 | 4170 | 4550 | 4570 |
| 3.1. | Сыерлар | бер. | 1680 | 1520 | 1580 | 1600 |
| 4. | Атлар | бер. | 350 | 355 | 358 | 360 |
| 6. | Сарыклар һәм кәҗәләр | бер. | 4095 | 4546 | 4610 | 4790 |
| 7. | Кош-корт | бер. | 19550 | 17500 | 18000 | 18500 |
| 8. | Умарталыклар | бер. | 3500 | 3550 | 3590 | 3650 |
| 9. | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт җитештерү күләмнәрен арттыру | мең литр | 8262,1 | 7500,0 | 7610,0 | 7820,0 |
| 10. | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда ит җитештерү күләмнәрен арттыру | тонн | 1267,4 | 1123,0 | 1130,0 | 1140,0 |
| 11. | 3 һәм аннан күбрәк сыер тотучы шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны | бер. | 155 | 153 | 156 | 160 |

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында шәхси ярдәмче
хуҗалыкларны тотрыклы үстерү»
муниципаль программасына
2нче кушымта

«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль
районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тотрыклы үстерү»
муниципаль программасының төп чаралары
исемлеге

| № п/п | Чара атамасы | Башкаручылар | Финанслау чыганаклары | Еллар буенча финанслай суммасы, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | барлыгы |
| 1. Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерүне стимуллаштыру (КФХ, ШЯХ) | | | | | | | |
| 1.1. | Өч һәм аннан да күбрәк сыерлары булган хуҗалыкларга һәм авыл җирендә яшәүче, 2 һәм аннан да күбрәк савым сыерлары булган 50 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнарга саву аппараты бирү | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, Баулы муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе (алга таба - БМР авыл хуҗалыгы идарәсе) (килешү буенча) | җирле бюджет | 322,5 | 367,5 | | 690,0 |
| 1.2. | Сөт юнәлешендәге кече фермалар төзүдә матди ярдәм күрсәтү | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе | җирле бюджет | 138,6 | 0,0 | | 138,6 |
| 1.3. | КФХ, ШЭ, гаилә фермалары төзүдә, шул исәптән җир кишәрлекләрен һәм биналарны рәсмиләштергәндә ярдәм күрсәтү юлы белән авыл җирендә эшкуарлыкны үстерүгә ярдәм | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, «Баулы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ (килешү буенча) | Финанслау таләп ителми | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.4. | Эш башлаучы фермерларга грантлар һәм (яисә) бер мәртәбә ярдәм алуда, шулай ук гаилә терлекчелек фермаларын үстерүдә консультатив ярдәм | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты | Финаслау таләп ителми | | | | |
| 2. Авыл халкын һәм авыл учреждениеләрен социаль төзекләндерү һәм аларга ярдәм итү | | | | | | | |
| 2.1. | Авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрү | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе | Финанслау таләп ителми | | | | |
| 2.2. | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүмат җиткерү | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, БМР авыл хуҗалыгы идарәсе | Финанслау таләп ителми | | | | |